КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 29 декабрь г.Казань № 1439

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга түләүле хезмәтләр төрләре яктылыгында Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәренең һәм әлеге керемнәрдән (акчасы шул исәптән максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш) хезмәт хакын түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә күләмнәренең план күрсәткечләрен билгеләү турында» 2022 ел, 25 ноябрь, 1261 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2023 елга түләүле хезмәтләр төрләре яктылыгында Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәр күләмнәренең һәм әлеге керемнәрдән (акчасы шул исәптән максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш) хезмәт хакын түләүгә җибәрелә торган чыгымнарның тәкъдим ителә күләмнәренең план күрсәткечләрен билгеләү турында» 2022 ел, 25 ноябрь, 1261 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр күләменең планлы күрсәткечләреннән арткан Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләре тарафыннан алынган түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр күләме, шул исәптән акчалары максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, алар тарафыннан «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе турында» 2017 ел, 21 сентябь, 705 нче карары белән

расланган Тешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе нигезендә билгеләнә торган күләмдә хезмәт хакы түләүгә җибәрелә;»;

4 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр күләменең планлы күрсәткечләреннән арткан тәкъдим ителгәннән артык алынган түләүле хезмәтләр күрсәтүдән керемнәр күләме, шул исәптән акчалары максатчан тотылырга тиешле керемнәрдән тыш, 2 нче һәм 3 нче кушымталарда билгеләнгән «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе турында» 2017 ел, 21 сентябь, 705 нче карары белән расланган Тешле финанс елына Татарстан Республикасы учреждениеләре тарафыннан түләүле хезмәтләр күрсәткәндә план күрсәткечләрен формалаштыру тәртибе нигезендә билгеләнә торган күләмдә хезмәт хакы түләүгә җибәрергә;»;

әлеге карарга теркәлгән 1 нче кушымтада:

4 нче графада:

«Барлыгы» юлында «1 644 261,0» саннарын «1 644 141,0» саннарына алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы» юлында «1 800,0» саннарын «1 680,0» саннарына алмаштырырга;

әлеге карарга теркәлгән 2 нче кушымтада:

4 нче графада:

«Барлыгы» юлында «5 351 708,0» саннарын «5 210 863,0» саннарына алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы» юлында «3 714 120,0» саннарын «3 573 275,0» саннарына алмаштырырга.

2. Бу карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин